Галим, З. Рәссамның "Бизәкле дөнья"сы / З. Галим // Шәһри Чаллы. – 2022. – №89 (7 декабрь). – Б. 5.







**Гөлсабира Хәкимова исемендәге картиналар галереясында күз явын алырлык матур, милли күргәзмә ачылды. Татарстан рәссамнар берлеге әгъзасы, декоратив-гамәли сәнгать остасы, 40 ел педагогик эшчәнлеккә ия рәссам Хәния Гәрәеваның 65 яшьлек юбилеена багышланган ул. Экспонатлар арасында ниләр генә юк: буяу белән ясалган төрле жанрдагы картиналар, сәйләннән эшләнгән рәсемнәр, чигүле тастымал, мендәр тышлары. Барысы да искиткеч матур итеп, җиренә җиткереп эшләнгән.**

# Рәссамның «Бизәкле дөнья»сы

Иҗат

*Зөлфия* **Галим**

Хәния Гәрәева 1992 елдан рәсем сәнгате һәм чигү белән профессиональ дәрәҗәдә шөгыльләнә. Ул калфак, түбәтәй, тастымаларны татар халкының милли үзенчәлекләрен күз уңында тотып бизи. Аның хезмәтләрен татарлар яшәгән барлык төбәкләрдә дә яратып карыйлар.

Күргәзмә ачу тантанасына зыялылар, укучылар, Хәния ханымның иҗатына гашыйк кешеләр килгән иде. «Хәниянең якты, милли иҗаты белән Мәскәү татарлары ел саен таныша. Ул Мәскәү сабан туена күңел җылысын биреп эшләгән милли баш киемнәрен, картиналарын, сөлгетастымалларын алып бара», – ди Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Дания Сибгатуллина.

Татарстанның халык артисты Резедә Шәрәфиева да талантлы авылдашы белән горурлана. «Иҗатыгыз белән Минзәлә районы Наратлы Кичү авылын данлаганыгыз, булганыгыз өчен рәхмәт, Хәния апа», – дип ул үзенең иң матур җырын бүләк итте.

Картиналар галереясы директоры Әлфия Гарипова, ТР Рәссамнар берлегенең Чаллы бүлеге рәисе Ленар Әхмәтҗанов һәм башкалар юбилярның иҗатын югары бәяләделәр, иҗади уңышлар һәм сәламәтлек теләделәр, бүләкләрен тапшырдылар.

Күзләрне иркәли, күңелләрне ял иттерә торган бай эчтәлекле күргәзмә гамәли сәнгатьтән ерак торучы кешеләр күңеленә дә хуш килде. «Без гаиләбез белән Хәния Гыйльметдинова иҗатына гашыйк», – диделәр Земфира һәм Равил Әхмәтҗановлар.